ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423740, Актанышбаш авылы,
Мәктәп ур., 19 йорт

СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423740, д. Актанышбаш, ул.
Школьная, дом 19

**РЕШЕНИЕ**
**20 июнь 2025 ел**

**КАРАР**
**№ 14**

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына вәкаләтләрне тапшыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү, муниципаль милек объектларын файдалануга бирү, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү буенча;
- җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан элек бирелгән вәкаләтләр буенча;
- муниципаль милектәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыруны һәм оештыруны гамәлгә ашыру;
- җирлекнең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә бирү һәм тартып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән дә;
- Җирлек җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советының 2006 елның 27 нояберендә 10 номерлы карарының 1 пунктчасының икенче абзацын һәм 2 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Актаныш муниципаль районы**
**Актанышбаш авыл җирлеге Советы рәисе** **Х.М.Хакимов**